ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МОНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2019 елның 23 сентябреннән № 143

«Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының
2019 елга һәм 2020, 2021 елларның план чорына
Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджеты турында»
исемле карарга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монай авыл җирлеге Советының
үзгәрешләр кертү турында.

Монай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Монай авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 декабрендәге 118нче номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 елларның план чорына «Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджеты турында» исемле карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяда 1 пунктның
1нче бүлекчәсендә «3885,37757» саннарын «3934,56328» саннарына үзгәртергә;
2нче бүлекчәсендә «3927,33875» саннарын «3976,52446» саннарына үзгәртергә;
1нче таблицаның 1нче кушымтасын «2019 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» яңа редакциядә бәян итәргә;

2. 3нче статьяның №2 кушымтасындагы 1нче таблицаны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетының 2019 елга фаразланган керемнәр күләме» яңа редакциядә бәян итәргә

5нче статьяда:
№5 кушымтасындагы 1нче таблицаны «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2019 елга бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) буенча бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә;
№6 кушымтасындагы 1нче таблицаны «2019 елга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монай авыл җирлеге муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә.

Монай авыл җирлеге
Советы рәисе Кириллов Р.М.